**Әдәби укудан эш программасына аннотация**

1-4 нче сыйныф өчен әдәби уку фәненнән эш программасы Дәүләт стандартының Федераль компонентына нигезләнгән башлангыч мәктәпләрнең әдәби уку фәненнән үрнәк программасына нигезләнеп төзелде:

Әдәби уку фәненнән эш программасы “Перспективалы башлангыч мәктәп” концепциясе һәм икенче буын гомуми белем бирү федераль дәүләт стандартлары таләпләренә туры килә. Программа яңа укыту стандартлары таләпләрен искә алып, үстерешле укыту принциплары белән традицион белем бирү принципларының үзара тыгыз бәйләнештә булуын тәэмин итә торган «Перспективалы башлангыч мәктәп» концепциясенә нигезләнеп эшләнгән.

**УКЫТУ-МЕТОДИК КОМПЛЕКТЫНЫҢ БУРЫЧЛАРЫ:**

«Әдәби уку» укыту-методик комплекты түбәндәге мәсьәләләрне хәл итә.

1. «Перспектив башлангыч мәктәп» комплекты чишәргә тиешле гомумдидактик бурычлар: укучы үзенә кирәкле информацияне «Эчтәлек»;битенә карап таба белергә; исеме буенча текстның эчтәлеген күзалларга; күзәтү эшчәнлеген формалаштырырга *(әдәби һәм сәнгать исәрләреннән аерым детальләрне таба, барлык ваклыклары белән сөйләп бирә)* һәм гомумиләштерергә *(аерым детальләргә нигезләнеп, таралган төрле мәгълүматларны берләштереп, бербөтен картина тудырырга);* «акыллы өлкәннәр» белән хат аша аралашу ихтыяҗы формалаштырырга тиеш.
2. Бала яшенә туры килә торган теоретик бурычлар:

а) хайваннар турындагы әкият үзенчәлекләре белән таныштыру: татар халык әкиятләренең, берьяктан, башка халыкларның хайваннар турындагы әкиятләренә охшаш булуы *(төп геройлары — хайваннар, еш кына бер ук төрле мөнәсәбәтләргә керәләр),* икенче яктан, бер-берсеннән аерылуы *(төп геройлар — башка төрле хайваннар, бер-берсе белән мөнәсәбәтләре бөтенләй башка төрле);* хайваннар турышдагы автор әкиятләренең еш кына халык әкияләренә нигезләнүе *(башлангыч сыйныфларда әле автор нигезләнүе термин буларак әйтелми);* халык әкиятләрендә аерым хайваннарның патшалык итүе *(баш булуы);* хайваннар турындагы әкият героеның һәрвакытта көчсезләрне яклаучы гына түгел, еш кына хәйләкәр, тиктормас, көлкегә калучы икәнлеге турында төшенчә бирү;

3. Әхлакый бурычлар: күзәтүчәнлек, хыяллана белүчәнлек, дуслар белән аралашу, ярата һәм яратыла белү – байлык һәм рухи кыйммәт икәнлеге турында күзаллау булдыру;
4. Эстетик бурычлар: матурлык - ул сине чолгап алган тирәлек, бары тик аны күрә белергә кирәкле турында төшенчә бирү;
5. Сөйләм телен үстерү бурычлары:

Текстта ориентлаша белергә өйрәтү: әсәрләрне өлешләргә бүлү, кирәк урынны табын укып күрсәтү, хис белән билдерелгән өзекнең эчтәлеген ачыклау; әдәби әсәрләргә бәя бирелгәндә һәм сәнгать әсәрләрен караганда предметка - бу «синең» әсәрне аңлау;идеяң икәнен җайлап төшендерү.

Дәреслек һәм дәреслек-хрестоматия, мөстәкыйль эш дәфтәре структуралары һәм идея эчтәлекләре буенча бер – берсенә бәйләнеп килә. Мәсәлән, дәреслекнең «Тылсымлы әкият кануннарын өйрәнәбез: үткәннәрне яңадан китереп, бүгенге тормыш белән бәйлибез», «Фольклорга нигезләнгән хикәяләү. Дастан, риваять һәм легендалар аша тарих белән танышабыз, ә автор әкиятләре хисләр дөньясына чакыра. », « Шагыйрьләр һәм рәссамнар иҗаты аша табигать һәм кешеләрнең матурлыгын аңларга өйрәнәбез», « Безгә кадәр яшәгән яшьтәшләребез тормышы белән танышабыз», “Матурлыкның безгә ничек тәэсир иткәнен аңларга тырышабыз”,
“Җирдә кеше булу өчен, кеше күпме юллар үтә?” , “Сәнгать дөньясының үзенә генә хас үзенчәлекләрен ачыклыйбыз”, “Үткәне булмаган халыкның киләчәге юк.Туган ил турында уйланабыз” бүлекләренә дәреслек – хрестоматиянеңһәм эш дәфтәреннең шул ук бүлекләре туры килә.

Дәреслек һәм мөстәкыйль эш дәфтәре дә бер үк максатларны тормышка ашыра.